ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2020 ел Баулы шәһәре № 118

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 248 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябренәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы каралар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 248 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябренәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы каралар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Баулы муниципаль районының гомумбелем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VII бүлектә:

7.1 пунктының бишенче абзацында “сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

7.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Аерым белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә бирелә.»;

7.7.1 пунктының беренче, дүртенче һәм унберенче абзацларында “сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

7.7.2 пунктының беренче абзацында “сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

15нче таблицаның атамасында “сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

күрсәтелгән Нигезләмәнең 1нче кушымтасында «Кызыксындыру характерындагы түләүләр алуга хокук бирә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Берлеге, Россия Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 2нче пунктын түбәндәге 2.6 пунктча белән тулыландырырга: эчтәлектәге:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе» |

Күрсәтелгән карар белән расланган Баулы муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

III бүлекнең 2 пунктында «беренче - икенче төркем белән» сүзләрен «бер-ике төркем белән» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 5.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар

өчен ике яшь төркемнәрендә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшь төркемендә хезмәт күрсәткән педагогик хезмәткәрләрнең һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендә эшләүчеләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәтнең авырлыгын исәпкә алып, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында»гы 2009 елның 2 июлендәге 546нчы карары үз көченә кергәнчегә кадәр түләнә торган күләмдә башкарыла.»;

күрсәтелгән Нигезләмәнең 1нче кушымтасында «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Берлеге, Россия Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 2нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2.6 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе» |

Күрсәтлгән карар белән расланган Баулы муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымтада «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Берлеге, Россия Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендә 1нче таблицаны түбәндәге эчтәлектәге 2.7 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.7. | «Мәгариф отличнигы» билгесе» |

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров